**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 21.02.2023** **№295**

**Махсус хәрби операциядә катнашучы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гражданнары гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итү буенча өстәмә чаралар турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренщ мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) (алга таба – гаиләләр) түбәндәге өстәмә ярдәм чараларын билгеләргә:

мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмасына чираттан тыш кабул итү хокукы бирү;

мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү;

муниципаль мәгариф оешмаларында 1 - 11 сыйныф укучыларын ике тапкыр түләүсез кайнар ризык белән тукландыру (иртәнге аш, төшке аш).

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә эшчәнлек башкаручы предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган

гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган түләүләр рәвешендә өстәмә социаль гарантияләр билгеләүне, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына өстәмә социаль ярдәм чаралары билгеләүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гражданнары гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итү буенча өстәмә чаралар турында» 2023 елның 12 гыйнварындагы 39 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин